**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ СТАРОКАДЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
ул.Советская, д.6, с.Старое Кадеево, 423117

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
**ИСКЕ КАДИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**

**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 6 йорт, Иске Кади авылы, 423117

тел./факс (84396) 3-13-25 email: Skad.Cmn2@tatar.ru

07.06.2021 ел №12

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**КАРАР**

2020 елның 29 маенда кабул ителгән «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегенең 2020 елга һәм 2021, 2022 еллар план чорына салым чыгымнары исемлеген раслау турында» 9 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге башкарма комитетының 2020 елның 26 мартындагы 5 номерлы «2020 елда Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында» карары белән (2021 елның 30 апрелендәге 10 номерлы үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибенең 6 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТТЕ:

1. 2020 елның 29 маендагы 9 номерлы карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «2020,2021 һәм аннан соңгы елларга Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген раслау турында»;
2. Карарның 1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Иске Кади авыл җирлегенең 2020, 2021 һәм аннан соңгы елларга салым чыгымнары исемлеген расларга».
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы
Иске Кади авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе Н.В.Мөктәсимов